СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» март, 2019 ел № 1

**«Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 нче маддәләренә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 123 нче номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (1 нче Кушымта).

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлаулар оештыручысы итеп – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;

- үткәрү вакыты – 2019 елның 07 июне, 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Апаз авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- 2019 елның 06 июненә кадәр каралучы мәсьлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү адресы – Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы,

Совет урамы, 18 нче йорт, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башкарма комитеты.

4. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- гамәлдәге законнар буенча һәм әлеге карарда билгеләнгән вакыт аралыгында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында йомгак ясарга һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» проектны 2019 елның 06 апреленнән дә соңга калмыйча Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә http://arsk.tatarstan.ru// веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм http://arsk.tatarstan.ru// веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606156857
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АПАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609003056

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгының
20___ елның «___» _____________
___ номерлы Карарына
1 нче Кушымта

**Проект**
**Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«__» ________, 2019 ел №

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатыннан һәм 2018 елның 03 августындагы 340-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы, 2018 елның 03 августындагы 342-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законнарын гамәлгә ашырып, Апаз авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кушымта буенча Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков